МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** / **БОЕРЫК**

21.03.2018 Казан ш. № 11-35

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында законны үтәүгә контрольлекне көчәйтү максатыннан чыгып, Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында” 19 сентябрь, 2017 ел, №431 Россия Федерациясе Президенты һәм “Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында” 11 декабрь, 2017 ел, № УП-1092 Татарстан Республикасы Президенты Указы басылып чыгуга бәйле рәвештә, б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 25.05.2016, № 11-60 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу буенча комиссиясе турында нигезләмәгә, түбәндәге эчтәлектәге 3.4.3 пунктын өстәп, үзгәреш кертергә:

«3.4.3. Бу Нигезләмәнең 3.2, 3.4, 3.4.1 пунктларында күздә тотылган нигезле бәяләмәләр түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

а) бу Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасындагы икенче һәм бишенче абзацларда һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яки уведомлениеләрдә бәян ителгән мәгълүматларны;

б) запрослар нигезендә дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынулы оешмалардан алынган мәгълүматларны;

в) бу Нигезләмәнең 3.1 пунктының «б» пунктчасындагы икенче һәм бишенче абзацларда һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләр яки уведомлениеләрне, шулай ук бу Нигезләмәнең 3.13, 3.15.1, 3.18 пунктлары нигезендә карарларның берсен яки башка карар кабул итү өчен рекомендацияләрне башлангыч карап тикшерү нәтиҗәләре буенча нигезле йомгакны.».

Министр Р.Р.Гайзатуллин